ГЛАВА МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2015 с. Майдан № 2

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 ст.1 пункты, Мәйдан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Мәйдан авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

- Мәйдан авылы җирлегенең Мәйдан авылында урнашкан зиратны төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев